КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 817

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – Министрлык) хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча 5 726,7 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән 338 берәмлек дип билгеләргә, шул исәптән:

134 берәмлек – Министрлыкның вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча 3 041,9 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән үзәк аппараты хезмәткәрләре;

204 берәмлек – Министрлыкның вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча 2 684,8 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән территориаль идарәләр һәм Экологик күзәтчелекне тәэмин итү буенча үзәк бүлеге хезмәткәрләре.»;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчаның унтугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәү һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өлешендә Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе тарафыннан җибәрелә торган комплекслы экологик рөхсәтнамәләр алуга заявкаларны һәм аларга теркәлә торган материалларны карап тикшерүне башкара;»;

3.3.2 пунктчаның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.16 пунктча өстәргә:

«3.3.16. Татарстан Республикасының ведомство буйсынуындагы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен (алга таба – учреждениеләр) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шул исәптән:

учреждениеләр төзү, аларны үзгәртеп оештыру, аларның типларын үзгәртү, аларны бетерү турындагы карарлар проектларын әзерли, аларның уставларын раслый һәм аларга үзгәрешләр кертә;

учреждениеләр эшчәнлегенең учреждение эшчәнлеген бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен бәяли;

хезмәт законнары һәм учреждениеләрнең хезмәт хокукы нормалары бирелгән башка норматив хокукый актлары үтәлешен ведомство контролендә тотуны гамәлгә ашыра;

учреждениеләргә аларның уставларында каралган төп эшчәнлек төрләре нигезендә юридик һәм физик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыра һәм раслый;

учреждениеләрне гамәлгә куючының башка функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел,

18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.3 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 4.3.13[1] пунктча өстәргә:

«4.3.13[1]. Объект төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре яки әлеге махсус саклана торган табигать территорияләренең саклана торган зоналары чикләрендә урнаштырылган очракта, махсус саклана торган табигать территорияләре турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү өлешендә Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе тарафыннан җибәрелә торган комплекслы экологик рөхсәтнамәләр алуга заявкаларны карап тикшерү;».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә гидрометеорологик мәгълүмат алу һәм алардан файдалану өлешендә табигатьне саклау чараларын финанслау тәртибен раслау турында» 2006 ел, 7 август, 403 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гидрометеорологик мәгълүмат алу һәм алардан файдалану өлешендә табигатьне саклау чараларын финанслау тәртибен раслау турында» 2006 ел, 7 август, 403 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2006 ел, 21 август, 428 нче;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт бюджет һәм казна учреждениеләре өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыруны оештыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин